РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» 11 2020 ел № 908

2021 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларның туклануын оештыру

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 ел, № 273-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 21.09.2020 ел, № 851 «2021 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» Карары, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының кайнар туклануын оештыру максатларында, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2021 елның 1 гыйнварыннан расларга:

- Урыссу ш. т. п. гомуми белем бирү учреждениеләре өчен 5-11 сыйныфларга бер көнгә туклану бәясен 46 сум 00 тиен күләмендә, шул исәптән:

- уку чорында бер укучыга бер көнгә 8 сум 00 тиен күләмендә субсидияләр,

- уку чорында бер укучыга бер көнгә 38 сум 00 тиен күләмендә ата-аналар кертеме суммасы;

- авыл гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучы 5-11 сыйныфларда белем алучы бер укучыга бер көнгә 43 сум 00 тиен күләмендә, шул исәптән:

- уку чорында бер укучыга бер көнгә 8 сум 00 тиен күләмендә субсидияләр;

- уку чорында бер укучыга бер көнгә 35 сум 00 тиен күләмендә ата-аналар взнослары суммасы.

2. Якынча унике көнлек менюны расларга. Бер көнлек меню бәясе азык-төлек продуктларына бу вакытта урнашкан бәяләргә (1 нче кушымта) карап билгеләнә.

3. Башлангыч гомуми белем алучы балаларны бер тапкыр кайнар аш белән тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны ташламалы туклануны оештыру тәртибе турында Нигезләмәне (2 нче кушымта) расларга.

5. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының финанс-бюджет палатасы тарафыннан «Мәгариф» тармагы буенча 2020 елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджетында әлеге максатларга каралган акчалар чикләрендә муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыру чыгымнарын финанслауны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарны **http://pravo.tatarstan.ru** Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://jutaza.tatarstan.ru. адресы буенча Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль сораулар буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
ТР Ютазы муниципаль районы С. П. Самонина

Г. М. Гыйләҗева
2-71-00

Кушымта 2
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карарына
24. 11. 2020 ел № 908

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучылар өчен ташламалы туклануны оештыру тәртибе турында**

1. Әлеге Нигезләмә гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүне оештыру максатларында түбәндәге категория укучылар өчен эшләнде:

Россия Федерациясе Президентының 1992 елның 5 маендагы 431 номерлы «Күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары» Указы нигезендә, 4 һәм аннан да күбрәк 18 яшькә кадәрге балалар булган гаиләләрдәге балаларны түләүсез бушлай кайнар туклану (иртәнге һәм төшке аш) белән тәэмин итәргә. Ташламалы туклану белән әлеге категория укучылар әгәр дә гаиләдә өч һәм аннан да күбрәк бала гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алса, тәэмин ителә;

- әти-әниләре 1 һәм 2 нче төркем инвалидлыкта булган балалар;

- опекага алынган балалар (Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органнары белән килешенеп).

Әлеге категориягә керүче балаларга адреслы социаль ярдәм гомуми белем бирү учреждениеләренең 2020 елга расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә ата-аналар түләвеннән өлешчә азат итү юлы белән гамәлгә ашырыла.

2. Ташламалы туклану җирле бюджет акчалары исәбеннән Урыссу поселогы гомуми белем бирү учреждениесе укучысына бер көнгә 1 укучыга 36 сум 00 тиен һәм авыл гомуми белем бирү укучысына 1 көнгә 33 сум 00 тиен күләмендә оештырыла.

3. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында санап үтелгән укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру өчен гомуми белем бирү учреждениеләрендә педагогик коллективтан укучыларны тукландыруны оештыру өчен җаваплы директор һәм ата-аналар комитеты вәкилләре кергән комиссияләр төзелә. Комиссия әгъзаларының гомуми саны өч кешедән дә ким булмаска тиеш.

Комиссия ата-аналардан яки аларны алмаштыручылардан гариза кергән көннән алып 3 эш көне эчендә җыела.

Комиссия карары ата-аналардан яисә аларны алмаштырган затлардан кергән гаризаларны карый башлаганнан соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча кабул ителә һәм комиссия утырышы беркетмәсендә теркәлә.

4. Сыйныф җитәкчеләре:

- ата-аналардан яки аларны алмаштыручы затлардан ташламалы туклану алу өчен гаризалар, гаилә хәле турында белешмә, гомуми белем бирү учреждениесендә белем алу турында белешмә, инвалидлык турында белешмә (таныклык), опека һәм попечительлек органының опека билгеләү турындагы карарының күчермәсе кабул ителә;

- гаризаларны алганнан соң, аларны өч көн эчендә комиссия каравына җибәрәләр;

- сыйныф укучыларының туклануын категорияләр буенча исәпкә алып баралар;

- укучылар һәм ата-аналар арасында мәктәп укучыларын тулысынча тукландыру кирәклеге турында аңлату эшләре алып баралар;

- барлык сыйныф укучылары да ашханәгә йөрүне контрольдә тоталар;

- сыйныф укучыларының тукланулары вакытында ашханәдә булалар.

5. Ата-аналар яки аларны алыштыручы затлар тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплы.

6. Гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләре:

6.1. Укучыларны категорияләр буенча ташламалы туклану белән тәэмин итү буенча боерыклар чыгара.

6.2. Укучылар исемлекләрен «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУга категорияләр буенча тәкъдим итәләр.

7. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ мәгариф учреждениеләренә, укучыларны тукландыруны оештыру, азык әзерләү технологиясен үтәү, азык-төлек блокларын һәм санитар нормаларны үтәү мәсьәләләрен оештыруны барып карап тикшерүне гамәлгә ашыра.